**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әсәй авылы № 1 « 29» гыйнвар 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районының Әсәй авыл җирлеге Башлыгын
бүләкләү хакында

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге Советының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 04 маендагы 13 номерлы карары нигезендә, җирле район әһәмиятендәге яңа ел чараларын әзерләү һәм уздыру буенча зур оештыру эшен исәпкә алып,

Әсәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге бюджеты Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата бүләкне - 25955 сум 86 тиен (Егерме биш мең тугыз йөз илле биш сум 86 тиен) акчаларыннан алырга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге Советына 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.М. Вәлиева